**СОВЕТ**
**КУРКАЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422730, Высокогорский район РТ,
п. ж/д. разъезда Куркачи,
ул. Гагарина, 7

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОРКАЧЫК**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422730, ТР Биектау районы,
Коркачык тимер юл разъезды поселогы,
Гагарин ур., 7

Тел./факс: +7(84365) 71-2-15,e-mail: Kurk.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«10» ноябрь 2016 № 42

**Коркачык авыл җирлеге Советының «Коркачык авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм санитария тәртибен тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 28 маендагы 177 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Коркачык авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү һәм санитар-эстетик торышны оештыруны тәэмин итү максатларында Коркачык авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

Коркачык авыл җирлеге Советының 2015 елның 28 маендагы 177 номерлы карары белән расланган Коркачык авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм санитария тәртибен тәэмин итү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Урып-җыю һәм төзекләндерү өчен аерым шартлар» 5 бүлегенең 15.2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.2.14 Автотранспорт чараларының ял итү, кешеләр күпләп җыела торган урыннарда, пляжларда, скверларда хәрәкәте, шулай ук:

- газоннарда, скверларда, паркларда, пляжларда, урыннардан читтә махсус билгеләнгән мәйданнарда транспорт чаралары стоянкасы һәм парковкасы;

- кешеләр күп була торган урыннарга, балалар мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләренә, сәламәтлек саклау учреждениеләренә турыдан-туры якын урында транспорт чараларын куеп тору, парковкалау;

- юлларга һәм авыл җирлеге урамнарына пычрак машиналар, механизмнар, грунт өслекле урамнардан башка техника алып чыгу;

- гомуми файдалану территориясендә автотранспортның озак вакытлы тукталышы.

2. Әлеге карарны игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль

районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Совет председателе,
Коркачык авыл җирлеге башлыгы Р. Ф. Салихҗанов